РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422050, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Шэмэрдэн авылы, Лермонтов
урам, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР

10.02.2021 — № 3

Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге
Советының 25.10.2019 ел №28 карары белән расланган
“Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең
муниципаль милек исемлегенә кертелгән милкен, шул
исәптән җир участокларын да(шәхси ярдәмче хуҗалык
алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак
төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш),
өченче затлар хокукыннан азат ителгән (хуҗалык алып
бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай
ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мелкәти
хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына
ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга
арендага һәм (яки) куллануга тапшыру өчен билгеләнгән,
муниципаль милек исемлегенә кертелгән милкен арендага
бирү Тәртибен раслау турында” карарына үзгәрешләр кертү турында

24.07.2007 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” № 209-ФЗ Федераль законның 14.1 статьясы нигезендә (08.06.2020 ел, №169-ФЗ үзгәрешләр белән), Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы

Карар итте:

1. Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №28 карары белән расланган “Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең муниципаль милек исемлегенә кертелгән милкен, шул исәптән җир участокларын да(шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш),еченче затлар хокукыннан азат ителгән (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга арендага һәм (яки) куллануга тапшыру өчен билгеләнгән, муниципаль милек исемлегенә кертелгән милкен арендага бирү Тәртибен раслау турында” карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.6 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“1.6. Исемлеккә кертелгән мелкәтне арендалаучылар-авыл хуҗалыгы кооперативлары булып торучы яисә эшчәнлекнең социаль әһәмиятле төрләре яки муниципаль программалар (подпрограммалар) белән билгеләнгән естенлекле эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, шәхси эшмәкәрләр булмаган һәм «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар булырга мөмкин, кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан тыш, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аларга ярдәм күрсәтелә алмый”

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru , җирлекнең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/rus/shemordan адресы буенча бастырып чыгарырга.

Авыл җирлеге башлыгы А.Н.Гәрәев